**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423008, РТ, Нурлатский район п. Заречный,
ул. Черемшанская, д.5

**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Черемшанская ур., 5нче йорт, ТР, Нурлат районы, Заречный авылы, 423008

Телефон: 8 (84345) 38613, факс 38613 E-mail: Zarech.Nur@tatar.ru, сайт: http://nurlat.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный п. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 3

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы, 26нчы йорт адресы буенча урнашкан Торнаяс авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында 1-50 санлы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2024 елның 10 апрелендә 11 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы буенча, 76нчы йорт янында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында 51-104 йортларда яшәүчеләрдән элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Торнаяс поселогында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез гражданнар җыенында элек расланган мәсьәләләргә үзгәрешләр кертүгә ризамы;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18 октябрендәге 2 номерлы карары»

Аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Нурлат муниципаль районы Зареченск авыл җирлегенең Турнояс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Торнаяс авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы Т.В Забойдулина